**Сәлахова Венера Хәмит кызы**, Уразай төп гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Татар теле, 6нчы сыйныф

# Тема: Үткән заман сыйфат фигыль

**Максат**:

1. **белем бирү:** затланышсыз фигыльләр турында белешмә бирү; сыйфат фигыль төшенчәсен формалаштыру; аның мәгънәсе, сыйфат һәм фигыль белән уртаклыгын, җөмләдәге вазифасын ачыклау;
2. **үстерү:** фикерләү, сөйләм күнекмәләрен һәм төркемдә эшли белүне үстерү;
3. **тәрбияви:** табигатькә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләүгә этәргеч ясау.

**Дәрес тибы**: яңа төшенчәләр формалаштыру дәресе.

**Җиһазлау:** электрон презентация, 6 сыйныф өчен дәреслек (Ф.Ю. Юсупов, Р.Р.Сәйфетдинов, Ч.М. Харисова. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2014) 124-126 битләр.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлашу.**

1. Укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү.

**ХАЙ ФАЙВ - тынычлану сигналын куллану**

2.Уңай психологик халәт тудыру.

**1.Укытучы**:- Исәнмесез, хәерле көн укучылар! Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр, диләр. Әйдәгез әле бер-беребезне яңа көн белән котлап, матур сүзләр әйтик әле. *Көтелгән җавап: Хәерле көн! Яңа көн тынычлык алып килсен! Көннәр имин булсын! Яңа көн күп бишлеләр алып килсен! һ.б.*

- Иртә таңнан балкып чыккан кояш та сезгә бары шатлык китерсен, йөзегездәге елмаюлар беркайчан да сүрелмәсен. Менә шундый матур теләкләр белән дәресебезне башлап җибәрәбез.

**2.Укытучы:**-Укучылар, яңа темага керешкәнче сыйфат фигыльне кабатлап китик.

--Сез хәзер **КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД** (опроси-опроси-обменяйся) структурасы

ярдәмендә бер-берегезнең белемнәрен тикшерерсез.

-Ә хәзер ак бит аласыз ,икегә бөклибез, баш өлешенә тема буенча сораулар язасыз, ә аска җавабын язабыз.(Моны эшләү өчен 2 минут вакыт бирелә.)

Ә хәзер,торабыз (Музыка астында) пар эзлисез, якында булган иптәшегезгә, соравыгызны бирәсез, җавабын тыңлыйсыз, җавап бирә алмаса булышасыз.Соңыннан, иптәшегезне мактыйсыз.

Бергә:”Рәхмәт, синең белән эшләргә миңа рәхәт булды!”

Группаларга карточкалар бирелә

Карточкада бирелгән сүзләрне балалар предметның билгесен белдергән

һәм предметның эше аркылы белдерә торганнарга аералар.

**1 группага**

Кызыл алма, коелган алма, чабылган болын, яшел болын, сары яфрак,

өзелгән яфрак, ак челтәр, бәйләнә торган челтәр, кадерле кунак, киләчәк кунак.
Балалар көй астында үзләренә пар эзлиләр.

**2 группага**

Яшел күлмәк,укылган китап,сөйләнгән сүз,зур алан,ак кар, үтелгән юл, истән чыкмый торган хәл, зәңгәр күк йөзе,әйтелмәгән васыять, сары чәчәк.

**3 группага**

Ал кофта, бара торган юл,укыган китап, сайрый торган кош, озын юл, килгән кунак, зәңгәр чәчәк, киләчәк ел, кара буяу, сөрелгән кыр.
Каршыңда утыручы иптәшең белән алышынып, тикшерәбез.

3. Белемнәрне тигезләү. *(2 нче слайд)*

Хәзерге заман сыйфат фигыль

↓

Затланышсыз,сөйләм вакытында булган үтәлгән яки үтәлмәгән эш-хәлне билге итеп белдерә

↓

-учы/-үче; -а/-ә, -ый/-и торган кушымчалар

↓

Җөмләдә хәбәр була.

**Үзбәя.**

б) ярым иҗади: хәзерге заман сыйфат фигыль кергән сүзтезмәләрне уку. *(китап укучы бала, эшли торган кеше, килә торган кунак һ.б.)*

**Үзбәя.**

5. УМ кую ситуациясе. *(3 нче слайд)*
Бирелгән модельне тутырып бетерергә, дәрескә уку мәсьәләсе куярга.

Сыйфат фигыль

↙ ↓ ↘

Хәзерге заман ? Киләчәк заман

- Димәк, бүген дәрестә затланышсыз фигыльләр турында сөйләшүне дәвам итәбез. Фигыльнең кайсы төре җитми?

Көтелгән җавап: *Үткән заман сыйфат фигыль.*

***Бүгенге тема**:**Үткән заман сыйфат фигыль***

**Үзбәя.** Тема тактага һәм дәфтәрләргә язылa.

**II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Тактада язылган  җөмләләргә игътибар итик әле.

1. Тактага язылган җөмләләрне уку. Калын хәрефле сүзләрне үзләре ачыклап килгән сүзләр белән язып алырга, сорау куярга, нинди җөмлә кисәге булып килүен ачыкларга.

***1)Яңгыр алдыннан купкан җил-давыл чыбыкларны өзгән.***

***2) Күләгәсе ял иттерә кырдаэшләп арганнарны.***

***3) Бәйрәмнәрне көткән кебек көтәм Казаныма кайтырларымны.***

Булдырдыгыз, молодцы!

Ә хәзер дәреслектән 272 нче күнегүне эшлибез.(Үткән заман сыйфат фигыльләрне үзе ияргән сүз белән табып әйтергә.)

1 нче җөмлә-йөргән юлларга

2 нче җөмлә – төшкән көннәр

3 нче җөмлә- киткән еллар, дигән чорлар

Эшләп бетергәннән соң кагыйдәне укыйбыз.

**Ял минуты. ФОЛОУ ЗЕ ЛИДЕР** (следуем за лидером) структурасы.

Без зезнең белән хәзер ял итәбез.Моның өчен бер-берегез артыннан тезелеп басабыз.Беренче алда басучы – лидер нинди хәрәкәтләр ясый, шуны эшлибез.Музыка бетүгә лидер алышына.

Рәхмәт!

Барыбыз да урыннарга утырабыз.

Хәзер без **КОНТИНИУС РАУНД РОБИН(продолжительный раунд робин) структурасы.**

Үткән заман сыйфат фигыльләр белән  җөмләләр төзибез һәм 4 нче номерлы укучы укый, аннан чират белән дәвам итәбез.(**3 минут вакыт бирелә)**

**Үзбәя.**

**Rouhd Rjbih-Раунд Робин(по часовой стрелке)**

2. Бирелгән фигыльләрдән үткән заман сыйфат фигыльне ясарга, аларга сыйфатланмыш табып язарга.

*(Карточкалар бирелә)*

*Фигыльләр:төрләнү,кыскарту,коену,хәзерләнү,юл күрсәтү,баю, чабу, уйнау, кою, бару.*

*Исемнәр:бүлмә,кояш,болын,балалар, сүз төркеме, юл, инеш,йолдыз, елга, кунак.*

*Төрләнгән сүз төркеме, кыскарган юл, коенган балалар, хәзерләнгән кунак, юл күрсәткән йолды,баеган кояш, чапкан болын, уйнаган балалар,койган инеш, барган кунак.(язалар,бер-берсенекен сәг.әйләнеше буенча тикшерәләр, үзләренә язалар)Чәче кара булганы укый.*

*(Карточкалар җыела)*

**Үзбәя.**

3. Сораулар буенча үткән заман сыйфат фигыльнең моделен төзү. *(5нче слайд)*

Үткән заман сыйфат фигыль

↓

Затланышсыз,сөйләм вакытына кадәр булган эшне билге итеп белдерә

↓

-ган/-гән, -кан/-кән кушымчалары

↓

Җөмләдә ия, аергыч, тәмамлык, хәл була.

- Үткән заман сыйфат фигыль нинди фигыль төркемчәсе, нәрсәне белдерә?
- Кайсы сүз төркемнәренең уртак билгеләрен үз эченә ала?
- Сыйфат һәм фигыль билгеләрен күрсәтегез.
- Нинди җөмлә кисәге булып килә.

Модельгә таянып, сыйфат фигыльгә билгеләмә бирү.

**Үзбәя.**

**III. Рефлексия, бәяләү.**

1. - Дәрестә нинди уку мәсьәләсе чиштек? Ничек чиштек? Нәрсәләр белдек?

*Көтелгән җаваn: Үткән заман сыйфат фигыль турында өйрәндек. Сыйфат һәм фигыль билгеләренә ия булуын белдек. Сыйфат фигыльне табуга күнегүләр эшләдек.*

2. Гомуми бәя кую.

3. Өй эше бирү:

1) 1 нче группага - тел турында үткән заман сыйфат фигыльләр кергән мәкальләр язып килегез.

2) 2 нче группага – үткән заман сыйфат фигыльләр кулланып, “Кышкы табигать” темасына кечкенә күләмле инша языгыз.

3) 274 нче күнегү